Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлегенең
Түбән Ушма авылында
ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«24» март, 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 25 статьясы нигезендә Балтач муниципаль районы Түбән Ушма авыл җирлегендә гражданнар җыены карар итте:

1. 2023 елның 25 ноябрендә Татарстан Республикасының Балтач муниципаль районының Кече Лызи авыл җирлегенең Түбән Ушма торак пунктында гражданнар җыелышы №2 карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 2 нче пункт түбәндәгечә расларга:

«2. Алынган акчаны түбәндәге эшне башкарып җирле әһәмияттәге проблемаларны чишү өчен кулланырга:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияткә ия булган җәмәгать юлларын төзү, ремонтлау, техник хезмәт күрсәтү (Түбән Ушма авылы Гагарина урамы буйлап юлларны норматив хәлгә китерү);

- торак пункт территориясен яхшырту (Түбән Ушма авылындагы балалар һәм спорт мәйданчыкларын һәм торак пункт территориясен ремонтлау һәм төзекләндерү; Түбән Ушма авылы Гагарин урамы буенча агачлар кисү).

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Кече Лызи авыл җирлеге башлыгы А.С.Исмагилов